**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 4-35-10 тел./факс +7(84396) 4-35-09, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.08.2024 **Чирмешән авылы** № 278

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Торгларда җир кишәрлеген арендага, милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 326 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 627-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Торгларда җир кишәрлеген арендага, милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 326 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.8.2.1 пунктының 13 нче пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «13) җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән яисә территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән, аны гамәлгә ашыру Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Россия Федерациясе яисә Россия Федерациясе субъекты билгеләгән юридик зат тарафыннан тәэмин ителә торган территория чикләрендә урнашкан».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе И.М.Җамалетдинов